Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

24 октябрь, 2019 ел № 223

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә, № 1, 2, 3 һәм 4 номерлы ачык тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге генераль планын кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге генераль планын территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов